**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕПИНЯЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2018 ел № 1

**«Сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында»**

"2018 елның 18 мартында Россия Федерациясе Президентын сайлау буенча басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар исемлеге турында" Татарстан Республикасы Зәй районы территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимен карап, “Россия Федерациясе Президентын сайлаулар турында” 2003 елның 10 гыйнварындагы 19-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясы 7 пункты, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының (07.05.2007 N 21-ТРЗ номерлы) 64 статьясы 8 пункты нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. "Россия Федерациясе Президентын сайлаулар турында" 2003 елның 10 гыйнварындагы 19-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясы 7-9 пунктлары нигезендә 2018 елның 18 мартында Россия Федерациясе Президентын сайлау буенча сайлау алды агитация материаллары урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегенең һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазларга.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге сайлау участоклары территориясендә сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру урыннары исемлеген кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны Зәй муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
4. Карарны Югары Пәнәче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **М.Х.Туктаров**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Югары Пәнәче авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 05 февралендәге
1 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге сайлау участоклары территориясендә сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру урыннары исемлеге

| № | Сайлау участогының номеры | Объектның исеме һәм урнашу адресы |
|---|---|---|
| 1. | 1468 | Югары Пәнәче авылы, Елга урамы, Үзәк урам,, мәгълүмати стендларда. |
| | | Урта Пәнәче авылы, Үзәк урам, мәгълүмати стендларда. |
| | | Түбән Пәнәче авылы, Х.Туфан урамы, Үзәк урам, мәгълүмати стендларда. |
| 2. | 1467 | Бура-Киртә авылы, Елга аръягы урамы, Үзәк урам, мәгълүмати стендларда. |
| | | Алмалы авылы, Яшел урам, 5 йорт. |